КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2019 ел, 2 ноябрь

г.Казань

№ 1008

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 965 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1262 нче; 2019 ел, 6 май, 380 нче; 2019 ел, 11 июль, 565 нче; 2019 ел, 28 август, 714 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

V бүлекнең 2 нче пунктындагы сигезенче абзацында «300» саннарын «550» саннарына алыштырырга;

VI бүлекнең 15 нче пунктында, 15.11 нче пунктындагы бишенче һәм җиденче абзацларда «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең V бүлегендәге 12 нче пунктта, 12.11 нче пункттагы бишенче һәм җиденче абзацларда «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең VI бүлегендәге 8 нче пунктта, 8.11 нче пункттагы бишенче һәм җиденче абзацларда «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең VI бүлегендәге 7.1 нче пунктта, 7.11 нче пункттагы бишенче һәм җиденче абзацларда «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Югары белем бирүнең мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмалары һәм Татарстан Республикасының өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

4.1 нче пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«K – югары белем бирүнең мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларының административ-хуҗалык һәм укыту-ярдәмче персонал, профессор-укытучылар составы хезмәткәрләре һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләре өчен 3кә тигез итеп кабул ителгән, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләре өчен 1,7гә тигез итеп кабул ителгән, өстәмә һөнәри белем бирүче «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт мәгариф учреждениесенең административ-хуҗалык һәм уку-укыту-ярдәмче персоналы, профессор-укытучылар составы хезмәткәрләре һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә, фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләре өчен 2гә тигез итеп кабул ителгән тармак өстенлегенең арттыру коэффициенты;»;

5.5.1 нче пунктта, 5.5.11 нче пунктның бишенче һәм җиденче абзацларында «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин